ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.09.2025 Олы Кайбыч ав. № 451

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кичкеево авылы янында «Август-Кайбыч» ҖЧҖнең тәүлеклек җайга салу бассейны булган сугару челтәрен төзү» линияле объекты территориясен планлаштыру проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында

Халыкның тормыш эшчәнлегенең уңай шартларына хокукларын, җир кишәрлекләре хокук ияләренең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кичкеево авылы янында «Август-Кайбыч» ҖЧҖнең тәүлеклек җайга салу бассейны булган сугару челтәрен төзү» линияле объекты территориясен планлаштыру проекты буенча гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кичкеево авылы янында «Август-Кайбыч» ҖЧҖнең тәүлеклек җайга салу бассейны булган сугару челтәрен төзү» линияле объекты территориясен планлаштыру проекты буенча гавами тыңлауларны 2025 елның 07 октябрендә 17.00 сәгатьтә Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 й. адресы буенча урнашкан Иҗтимагый үзәк бинасының актлар залында уздырырга.

3. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кичкеево авылы янында «Август-Кайбыч» ҖЧҖнең тәүлеклек җайга салу бассейны булган сугару челтәрен төзү» линияле объекты территориясен планлаштыру проекты материаллары (текстлы һәм график өлеш) белән эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин:

- Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7й., 2нче кат, 209 нчы кабинет ;
- Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Надеждино ав., Клуб ур., 1й.;
- Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Ульянково ав., Мәктәп ур., 39й.;

- Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Багай ав., Үзәк ур., 28й.

3.1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кичкеево авылы янында «Август-Кайбыч» ҖЧҖнең тәүлеклек җайга салу бассейны булган сугару челтәрен төзү» линияле объекты территориясен планлаштыру проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җыю урыны итеп Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 нче йорт, 2 нче кат, 209 нчы кабинет адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеген билгеләргә.

4. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә:

- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кичкеево авылы янында «Август-Кайбыч» ҖЧҖнең тәүлеклек җайга салу бассейны булган сугару челтәрен төзү» линияле объекты территориясен планлаштыру проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында мәгълүмат урнаштырырга;

- әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Е.Г. Давыдовага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров